МИНИСТЕРСТВО КУЛЬТУРЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӘДӘНИЯТ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

20.06.2018 г. г. Казань № 650 од

Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының дәүләт граждандык хезмәткәрләренең эштә үзләрен тоту таләпләре һәм мәнфәгатьләр низагларын җайга салу буенча Комиссиясе турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Президентының 2017 елның 19 сентябрендәге "Коррупциягә каршы көрәш турындагы законнарны үтәүне контрольдә тотуны көчәйтү максатларында Россия Федерациясе Президентының кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында"гы 431нче Указы һәм Татарстан Республикасы Президентының 2017 елның 11 декабрендәге "Татарстан Республикасы Президентының коррупциягә каршы көрәш мәсьәләләре буенча аерым указларына үзгәрешләр кертү турында"гы УП-1092 номерлы Указы басылуга бәйле рәвештә

**боерам:**

Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының 2016 елның 24 мартындагы 240 од боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының дәүләт граждандык хезмәткәрләренең эштә үзләрен тоту таләпләре һәм мәнфәгатьләр низагларын җайга салу буенча Комиссиясе турындагы Нигезләмәгә түбәндәге эчтәлекле 3.6.1 пунктын өстәп үзгәрешләр кертергә:

"3.6.1. Әлеге Нигезләмәнең 3.2, 3.4, 3.5 пунктлары белән каралган нигезле нәтиҗәләрдә түбәндәгеләр булырга тиеш:

а) әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктының Б» һәм «Д» ярдәмче пунктларының икенче һәм бишенче абзацларында күрсәтелгән мөрәҗәгать һәм хәбәрләрдә язылган мәгълүмат;

б) запрослар нигезендә дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм кызыксынган оешмалардан алынган мәгълүмат;

в) әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктының Б» һәм «Д» ярдәмче пунктларының икенче һәм бишенче абзацларында күрсәтелгән мөрәҗәгать һәм хәбәрләрне башлангыч карау нәтиҗәләре буенча нигезле өземтә, әлеге Нигезләмәнең 3.16, 3.19, 3.22 пунктлары нигезендә караларның берсен кабул итү өчен киңәшләр".

**Министр вазифаларын башкаручы** **Э.Р. Камалова**